# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы «Майна авыл җирлеге» Чуваш Майнасы торак пунктында

2024 елның 11 апреленнән № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы «Майна авыл җирлеге» Чуваш Майнасы торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Майна авыл җирлегенең Чуваш Майнасы торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» 2023 елның 12 октябрендәге 2 номерлы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертергә, чараларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

1) торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту;

2) тышкы яктырту урам челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау;

3) торак пункт территориясен төзекләндерү;

4) ремонт, коймалар төзү, традицион күмү урыннарын төзекләндерү;

5) су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

6) каты коммуналь калдыклар туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыклар җыю өчен контейнерлар сатып алу, санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү;

7) беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү;

2.Әлеге карарны Майна авыл җирлеге мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында (http:// alekseevskiy.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Алексеевск муниципаль районы
Майна авыл җирлеге башлыгы Я.Д.Иванов